Гыйбадуллина, Лилия. Язар чагың / Лилия Гыйбадуллина // Чулман: альманах: мәкаләләр, шигырьләр, хикәяләр / [төзүчесе һәм кереш сүз авторы Г. Закирова]. – Казан: Татар китап нәшрияты, 2024. – Б. 101-102.



**Лилия Гыйбадуллина**

# ЯЗАР ЧАГЫҢ

*Ни соң ул шигырь? Аны ничек язарга? Шигырьне бәндә язамы, әллә шигырь — бәндәнеме?..*

Адәм баласы өчен ике ышык урын бар: тәүгесе әнкәйләрнең йөрәк асты булса, соңгысы — җир куены. Бер кочактан аерылгач, ахыргысына барып сыенганчы, җир белән күк арасында чәбәләнәсе. Фани дөнья утарында урын эзләп бәргәләнәсе. Ә аның чикләрен тарсынучылар табылмый калмый, шөкер. Хәтта мәхлук малтуарның да, киртә җимереп, киң җәйләүдә уйнакларга җөрьәт итүчесе табыла бит, сыртына чыбыркы сыдырасыларын белсә-белмәсә дә... Фанилык аратасын тарсынып тибенүчеләр, канат эзләүчеләр — шагыйрьләрдер.



Таң атканда, кулларыңны күккә күтәреп, кояшны сәламләгәнең бармы? Учларыңа көн тулганын, күзләреңә кот коелганын тоясыңмы шул мәлдә? Караңгылык чаршавы артындагы төнге йолдызларның якынлыгыннан башың әйләнәме? Әйләнә... Бу язуым — сиңа һәм синдәйләргә. Фани дөньяның фәкать бер тирмә икәнен, аның аръягында нидер барлыгын тоясың ич. Яшәү дигәннәре көн уздыру, тән туздыру гына түгелдер ләбаса. Чик бар икән, димәк, чиксезлек тә бар. Чик — чиксезлекне чикләү өчендер ул... Һәм киртәләрне җимерәсе килә. Язын. Кояш дөньяны кар кабыгыннан арындырган чакта. Яфрак — бөредә, таңнар — бәллүр, сулар — дуамал, кан кайнарлыгыннан йөрәк иләс вакытта. Шуңа да шагыйрьләрнең иң җилле, кояшлы шигырьләре яшьлектә языладыр. Синең дә язар чагың — хәзер, бүген.

Яшь дустым, каләмдәшем, азмы-күпме язганнарымнан, кичергәннәремнән чыгып, сиңа берничә киңәш бирергә җөрьәт итәм.

***Укы.*** Үзеңә кадәр язылганнарны укы, той, өйрән, чагыштыр. Кесәңдә шигырь китабы йөртсәң бигрәк тә яхшы. Гадәттә, чын шигырь китаплары кесәгә сыярлык була ул. Сүз уңаеннан, шигырь китабы белән фал ача беләсеңме? Сынап кара. Шигырь укы. Юна торгач, агач түмәре нәфис сынга әверелгән кебек,

укый-укый, зәвыгыңны нәфисләндер. Татар шигыре — бик борынгы һәм бик бай мирас ул. Асылда, ул — синең төп остазың.

***Яз.*** Иртәгәгә калдырма. Вакытны кармакка каптырып булмаган кебек, шигырьне дә маяга калдырып булмый. Калебеңә шигырь кагылган икән, син аны язарга тиеш. Нәфрәтеңне дә, мәхәббәтеңне дә, сагышыңны да — барысын да шигырь итеп яз. Йөрәгең белән яз. Яз. Юкса язылмаган шигырең җәза булып кайтачак. Чәчләрең чаларгач, мескен үкенеч, кысыр такмаза булып…

***Кадерлә.*** Шигырьне, йөрәгеңдә ул салган очкынны кадерлә, хөрмәт ит. Һәм сине сайлавына рәхмәтле бул. Сакла аны, дорфаланма, шапырынма. Шигырь дан да түгел, мал да түгел, бәхет тә түгел. Язмыш ул. Сиңа язылган икән — кадерлә, горурлан. Теләсә кайсы халыкның, мәдәниятнең, чорның йөзен әдәбият билгели. Әйтик, кайсы цивилизация турында «анда фәлән тонна нефть чыгарганнар, фәлән футболчы булган, төгән хәтле икмәк үстергәннәр» дигәнне укыганың бар, йә? Әдәбиятның йөзен исә шигырь билгели. Тарихның йөзен шигырь билгели.

***Тугры бул.*** Асыл шигырь гавам өчен язылмый, үзең өчен, йөрәгеңнән өзеп языла. Гавам зәвыгына да яраклашма. Исәпләш, күзәт, ләкин яраклашма. Һәр сыек җилгә сыгылып торырга саз каены түгелсеңдер. Үзеңне сакла, сатма, сатылма.

***Ялкауланма.*** Әдәби иҗат — иң авыр хезмәт. Тән саулыгын да, җан саулыгын да ала торган, йөрәк егәре таләп итә торган хезмәт ул. Җиңеллеккә өметләнмә. Көн саен язарга, укырга, язганнарыңны редакцияләргә вакыт табарга тырыш. Язучы өчен дисциплина, тәртип бик мөһим. Күңелеңдә иҗат очкыны бар икән, гомереңне башкага әрәм-шәрәм итмә.

Баш өстеңдә кояшлы зәңгәр күк бар, табан астында хәтер һәм бәрәкәт тулы кара җир бар. Шушы ике арада син үтәсе матур юл җәйрәп ята. Шигырьле, гамьле, иркен булсын ул. Уңышлар сиңа. Без сиңа ышанабыз.